**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О свободе совести и о религиозных объединениях»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 сентября 2021 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 14 июля 1999 года № 2279 «О свободе совести и о религиозных объединениях» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1999, № 8 (II часть); 2001, № 12; 2004, № 2 (I часть); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I часть); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I часть), № 10 (I часть); 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I); 2018, № 54 (часть I); 2019, № 49 (часть I); 2020, № 26 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 4:
а) пункт 4 дополнить предложением следующего содержания: «Запрещается вовлечение малолетних в религиозные объединения, а также обучение малолетних религии вопреки их воле и без согласия их родителей или лиц, их заменяющих.»;
б) пункт 7 признать утратившим силу;

2) в статье 5:
а) в абзаце четвертом пункта 2 слова «федеральному закону» заменить словами «законодательству Российской Федерации»;
б) в пункте 8 слово «членов» заменить словом «участников»;

3) статью 6 дополнить пунктом 10 следующего содержания:
«10. Духовные образовательные организации проводят аттестацию, реализуют дополнительные профессиональные программы для священнослужителей и составляющих религиозный персонал религиозных организаций лиц, прошедших в зарубежных образовательных организациях (центрах) обучение по образовательным

программам, направленным на подготовку служителей и религиозного персонала религиозных организаций.»;

4) в статье 9:

а) дополнить пунктом $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Не может быть руководителем (участником) религиозной группы:

иностранный гражданин или лицо без гражданства, в отношении которых в установленном законодательством Российской Федерации порядке принято решение о нежелательности их пребывания (проживания) в Российской Федерации;

лицо, включенное в перечень в соответствии с пунктом 2 статьи 6 Федерального закона от 7 августа 2001 года № 115-ФЗ «О противодействии легализации (отмыванию) доходов, полученных преступным путем, и финансированию терроризма» (далее – Федеральный закон «О противодействии легализации (отмыванию) доходов, полученных преступным путем, и финансированию терроризма»);

лицо, в отношении которого вступившим в законную силу решением суда установлено, что в его действиях содержатся признаки экстремистской деятельности;

физическое лицо, в отношении которого межведомственным координационным органом, осуществляющим функции по противодействию финансированию терроризма, принято решение о замораживании (блокировании) денежных средств или иного имущества в соответствии со статьей $7^4$ Федерального закона «О противодействии легализации (отмыванию) доходов, полученных преступным путем, и финансированию терроризма», до отмены такого решения.»;

б) абзац второй пункта 2 изложить в следующей редакции:

«Религиозная группа представляет уведомление о продолжении своей деятельности не реже одного раза в год со дня последнего уведомления органа, уполномоченного принимать решение о государственной регистрации религиозной организации, в порядке, установленном Федеральным законом от 26 сентября 1997 года № 125-ФЗ «О свободе совести и о религиозных объединениях».»;

5) в статье 10:

а) пункт 4 дополнить абзацами следующего содержания:

«Религиозные организации вправе входить в структуру централизованной религиозной организации, выходить из нее или могут быть исключены из структуры централизованной религиозной организации, если такое право религиозных организаций, а также основания и порядок их вхождения в структуру централизованной религиозной организации, выхода и (или) исключения из нее определены уставом централизованной религиозной организации, в структуру которой они входят, и соответствуют ее внутренним установлениям.

Устав централизованной религиозной организации в соответствии с ее внутренними установлениями может предусматривать запрет на выход и (или) исключение религиозных организаций из централизованной религиозной организации, в структуру которой они входят.»;

б) в пункте 5 слова «учреждение или» исключить, слово «созданные» заменить словом «созданная», слово «имеющие» заменить словом «имеющая», слово «учреждение» заменить словом «организация»;

в) пункт 6 дополнить абзацем следующего содержания:

«Сведения о вероисповедании могут также содержаться в наименованиях юридических лиц, учредителями (участниками) которых являются религиозные организации. Иные юридические лица, за исключением юридических лиц, зарегистрированных в организационно-правовой форме общественной организации или общественного движения, не вправе включать в свои наименования сведения о вероисповедании. Юридические лица, зарегистрированные в организационно-правовой форме общественной организации или общественного движения, вправе включать в свои наименования сведения о вероисповедании на основании письменного согласия централизованной религиозной организации соответствующей конфессиональной принадлежности.»;

6) в пункте 3 статьи 11:

а) в абзаце первом слово «, членом» исключить;

б) абзац третий изложить в следующей редакции:

«лицо, включенное в перечень в соответствии с пунктом 2 статьи 6 Федерального закона «О противодействии легализации (отмыванию) доходов, полученных преступным путем, и финансированию терроризма»;»;

7) в пункте 2 статьи 12:

а) в абзаце втором слова « – ее наименование» заменить словами «и (или) иностранной религиозной организации их наименования»;

б) в абзаце третьем слова «основные формы» заменить словом «виды»;

8) статью 17 дополнить пунктом $3^1$ следующего содержания:

«$3^1$. Священнослужители и составляющие религиозный персонал религиозных организаций лица, прошедшие в зарубежных образовательных организациях (центрах) обучение по образовательным программам, направленным на подготовку служителей и религиозного персонала религиозных организаций, и впервые приступающие к совершению богослужений, других религиозных обрядов и церемоний, осуществлению миссионерской или преподавательской деятельности на территории Российской Федерации, до начала совершения богослужений, других религиозных обрядов и церемоний, осуществления миссионерской или преподавательской деятельности на территории Российской Федерации получают дополнительное профессиональное образование в сфере основ государственно-конфессиональных отношений в Российской Федерации в духовных образовательных организациях, зарегистрированных в соответствии с Федеральным законом от 26 сентября 1997 года № 125-ФЗ «О свободе совести и о религиозных объединениях» и реализующих имеющие государственную аккредитацию основные образовательные программы высшего образования, или в федеральных государственных образовательных организациях высшего образования Российской

Федерации, перечень которых утверждается федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по нормативно-правовому регулированию в сфере государственной регламентации образовательной деятельности, и проходят аттестацию в руководящем органе (центре) зарегистрированной на территории Российской Федерации централизованной религиозной организации соответствующей конфессиональной принадлежности в порядке, установленном законодательством Российской Федерации.»;

9) статью 30 дополнить пунктом $3^1$ следующего содержания:

«$3^1$. Юридические лица, в наименованиях которых содержатся сведения о вероисповедании, за исключением юридических лиц, зарегистрированных в организационно-правовой форме общественной организации или общественного движения, получивших указанное в пункте 6 статьи 10 настоящего Закона письменное согласие централизованной религиозной организации соответствующей конфессиональной принадлежности, должны до 1 января 2022 года привести свои наименования в соответствие с требованиями пункта 6 статьи 10 настоящего Закона.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
07 октября 2021 года
№ 78-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:
а) 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Кече яшьтәгеләрне дини берләшмәләргә җәлеп итү, шулай ук кече яшьтәгеләрне, аларның ихтыярына каршы килеп һәм ата-аналарының яисә аларны алмаштыручы затларның ризалыгыннан башка, дингә өйрәтү тыела.»;
б) 7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяда:
а) 2 пунктның дүртенче абзацында «федераль законга» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарына» сүзләренә алмаштырырга;
б) 8 пунктта «берләшмәләр әгъзаларының» сүзләрен «берләшмәләрдә катнашучыларның» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:
«10. Дин белеме бирү оешмалары чит ил мәгариф оешмаларында (үзәкләрендә) дини оешмаларның руханиларын һәм дини персоналын әзерләүгә юнәлдерелгән уку-укыту программалары буенча белем алган дини оешмалар дин әһелләренә һәм дини персоналын тәшкил иткән затларга аттестация үткәрә, алар өчен өстәмә һөнәри программаларны гамәлгә ашыра.»;

4) 9 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1[1] пункт өстәргә:

«1[1]. Түбәндәгеләр дини төркем җитәкчесе (анда катнашучы) була алмый:

Россия Федерациясендә булуы (яшәве) хупланмау турында карар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат;

«Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – «Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» Федераль закон) 6 статьясындагы 2 пункты нигезендә исемлеккә кертелгән зат;

үз көченә кергән суд карарында гамәлләрендә экстремистлык сыйфатлары булу билгеләнгән зат;

террорчылыкны финанслауга каршы тору функцияләрен гамәлгә ашыручы ведомствоара координация органы тарафыннан «Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» Федераль законның 7[4] статьясы нигезендә акчаларыннан яисә башка мөлкәтеннән файдалануын туктатып тору (туктату) турында карар чыгарылган физик зат, мондый карар юкка чыгарылганга кадәр.»;

б) 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дини төркем дини оешманы дәүләт теркәвенә алу турында карар кабул итәргә вәкаләтле органга соңгы тапкыр хәбәр иткән көннән алып елына кимендә бер мәртәбә «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлеген дәвам итү турында хәбәрнамә бирә.»;

5) 10 статьяда:

а) 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әгәр дини оешмаларның үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керү, аннан чыгу хокукы, шулай ук аларның үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керү, аннан чыгу һәм (яисә) аннан чыгарылу нигезләре һәм тәртибе алар структурага кергән үзәкләштерелгән дини оешма уставында билгеләнгән булса һәм аның эчке билгеләүләренә туры килсә, дини оешмалар үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керергә, аннан чыгарга хокуклы була яисә үзәкләштерелгән дини оешма структурасыннан чыгарыла ала.

Үзәкләштерелгән дини оешманың уставында, аның эчке билгеләүләренә нигезләнеп, дини оешмаларның алар структурага кергән үзәкләштерелгән дини оешмадан чыгуына һәм (яисә) чыгарылуына тыю каралырга мөмкин.»;

б) 5 пунктта «учреждение яки» сүзләрен төшереп калдырырга, «учреждение» сүзен «оешма» сүзенә алмаштырырга;

в) 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кайсы диннеке булуы турында белешмәләр шулай ук дини оешмалар тарафыннан гамәлгә куелган (аларда катнашучылар булган) юридик затларның

исемнәрендә күрсәтелергә мөмкин. Башка юридик затлар, оештыру-хокукый рәвеше иҗтимагый оешма яисә иҗтимагый хәрәкәт буларак теркәлгән юридик затлардан тыш, кайсы диннеке булуы турында белешмәләрне үз исемнәренә кертергә хокуксыз. Оештыру-хокукый рәвеше иҗтимагый оешма яисә иҗтимагый хәрәкәт буларак теркәлгән юридик затлар, тиешле конфессиядәге үзәкләштерелгән дини оешманың язма ризалыгына нигезләнеп, кайсы диннеке булуы турында белешмәләрне үз исемнәренә кертергә хокуклы.»;

6) 11 статьяның 3 пунктында:

а) беренче абзацта «, әгъзасы» сүзен төшереп калдырырга;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» Федераль законның 6 статьясындагы 2 пункты нигезендә исемлеккә кертелгән зат;»;

7) 12 статьяның 2 пунктында:

а) икенче абзацта «караса, аның да исеме» сүзләрен «һәм (яисә) чит ил дини оешмасына караган очракта аларның исемнәре» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта «төп рәвешләре» сүзләрен «төрләре» сүзенә алмаштырырга;

8) 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Чит ил мәгариф оешмаларында (үзәкләрендә) дини оешмаларның руханиларын һәм дини персоналын әзерләүгә юнәлдерелгән уку-укыту программалары буенча белем алган һәм Россия Федерациясе территориясендә тәүге тапкыр гыйбадәт кылырга, башка дини йолалар һәм тантаналар үткәрергә, миссионерлык һәм хәлфәлек эшчәнлеген гамәлгә ашырырга керешүче дини оешмаларның дин әһелләре һәм дини персоналы булган затлар Россия Федерациясе территориясендә гыйбадәт кылуны, башка дини йолалар һәм тантаналар үткәрүне, миссионерлык һәм хәлфәлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруны башлар алдыннан «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә теркәлгән һәм дәүләт аккредитациясенә ия булган югары белем бирү төп уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дини белем бирү оешмаларында яисә белем бирү эшчәнлеген дәүләт җайга салуы өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы тарафыннан исемлеге раслана торган Россия Федерациясенең федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә һөнәри белем алалар һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән тиешле конфессиядәге үзәкләштерелгән дини оешманың идарә итүче органында (үзәгендә) аттестация узалар.»;

9) 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Исемнәрендә кайсы диннеке булуы турында белешмәләр булган юридик затлар, оештыру-хокукый рәвеше иҗтимагый оешма яисә иҗтимагый хәрәкәт буларак теркәлгән, тиешле конфессиядәге үзәкләштерелгән дини оешманың әлеге

Законның 10 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән язма ризалыгын алган юридик затлардан тыш, 2022 елның 1 гыйнварына кадәр үз исемнәрен әлеге Законның 10 статьясындагы 6 пункты таләпләренә туры китерергә тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 07 октябрь
№ 78-ТРЗ